| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.09.2023 п.г.т.Алексеевское № 319

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 30.12.2022 ел, №585 «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын финанслау күләме үзгәрү сәбәпле һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.02.2022 № 244-р боерыгы нигезендә

**карар бирәм:**

1. «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында Башкарма комитетның 30.12.2022 ел, №585 карары белән расланган «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә (алга таба-Программа):

- Программаның 6 нчы «Программаны финанс белән тәэмин итү» бүлеген таблица белән тулыландырга (1 нче кушымта);
- Программаның 7 нче « Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү» бүлеген таблица белән тулыландырырга ( 2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
06.09.2023 ел № 319
карарына 1 нче кушымта

| № т/б | Чара исеме | Финанс чыгымнары (җирле бюджет) мең сум | | | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 | 2024 | 2025 | |
| 1 | Ясалма бозлы ябык шугалакны оператив идарә итү хокукына беркетү белән бәйле рәвештә, ТР АМРның «Кышкы спорт төрләре буенча спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ эшчәнлеген финанс яктан тәэмин итү. Хоккей һәм тимераякта фигуралы шуу спорт төрләрен кертү һәм үстерү | 342,26 | - | - | 342,26 |
| | | Финанс чыгымнары (республика бюджеты) мең сум | | | Барлыгы |
| | | 2023 | 2024 | 2025 | |
| | | 8002,7 | - | - | 8002,7 |
| ГОМУМИ: | | 8344,96 | - | - | 8344,96 |

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
06.09.2023 ел № 319
карарына 2 нче кушымта

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. Спорт төрләрен үстерүдә өстенлекләр | | | |
| 6.1 | Хоккей һәм тимераякта фигуралы шуу спорт төрләрен кертү һәм үстерү | 2023-2024 | ЯЭСТ һәм ББЭБ, МБ |